Бәрәнге һәрберебез яраткан ризыкларнын берсе булып кала инде.
Мордовиядә быел без аны торле вакытта - апрель ае азагыннан алып майнын сонгы атнасына кадәр утырттык. Шуна торле вакытта жыеп алабыз да. Кvбебез, бәрәнгенен тиз олгерә торган сортларын утыртканга, бакчаларында бәрәнге жирен кышлыкка дип казып та чыкты.
Янгырлар кvп иттереп яугач, жыярга ашыгырга ярамый, ләкин бу эшне сузарга да ярамый, ди тәжрибәле бакчачылар. Беренче чиратта бәрәнгенен сабагына карыйбыз, икән. Ин тогәл билгеләрнен берсе: әгәр ул чери, кибә, саргая башласа, димәк, ике атнадан казырга була.   Кабыкнын калынлыгын бәяләргә момкинлек бирә торган сынау да ярдәмгә килә. Әгәр ул артык юка булса, бәрәнгегә тагын 7 кон бирергә кирәк, ди бакчачылар. Идеаль һава торышы да сонгы рольне уйнамый. Бәрәнгене коры һәм кояшлы конне казу яхшырак. Болытлы, әмма янгырсыз булса - шулай ук яхшы. Әгәр бу вакытта әле жинел жил булса, ул озак саклауга жибәрер алдыннан унышны тизрәк киптерергә ярдәм итәчәк.
Белгәнебезчә, авыл халкы гына тvгел, vз йорты белән яшәгән шәһәр халкы да бакчасында бәрәнге vстерергә тырыша. Ә менә тәжрибәле бакчачылар зур булмаган бакчада да берничә торле сорт бәрәнге vстереп унышын жыя. Мәсәлән, сары бәрәнге тиз олгерә торган. Уртача олгерә торганнары бераз vсми торды быел никтер, аннар янгырлар яугач, vсеп киттеләр. Әмма Мордовиянен конбатыш районнарында боз яуганга, бәрәнге унышы vткән елдагыга караганда аз.
Ностальгия – vткәннәрне дә сагынып алыйк. Элек-электән бәрәнге алу - авыл халкы очен бәйрәм кебек булган. Бакчалар зур, гектарлап бәрәнге кыры. Аны гаиләләр берләшеп тә, омәләр ясап та алганнар. Бvген, кvбесенчә, кvп утырт-мыйлар һәм гаиләләре белән генә алалар. Трактор агрегаты бәрәнгене казып чыгарса, шул вакыт ярдәмгә килеп жыялар. Ә корәк-сәнәк белән казучылар – vзләре генә чvпли.
Мордовиядә сентябрьдә шәхси бакчаларда гына тvгел, фермерларнын һәм авыл хужалыгы предприятиеләренен бәрәнге кырларында да урак ае булды. Дорес, «икенче икмәк» житештерvчеләр саны алай ук кvп тvгел тvгелен. Тобәк очен традицион яшелчә культурасын бу сезонда фермерлар һәм авыл хужалыгы предприятиеләре бары тик 9 районда гына 480 гектар мәйданда утыртканнар. Анын ин зур мәйданы - 200 га Темниково районында, ә бәрәнге минимумы буенча беренчелекне нибары 1 гектар кvрсәткече белән Ковылкино районы тота. Бәрәнгене әлегә Темниково һәм Октябрь районнарында да жыялар. Беренчесендә бер гектарга 200 ц ундырышлылык белән 340 тоннадан артык жыеп алганнар, икенчесендә - 194 ц ундырыш белән 62 тоннадан артык уныш жыеп алынган. Ел унышын жыю дәвам итә.

Н.ХӘЛИЛ